Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы
КАРАРЫ

2025 елның 14 октябрендагы № 17

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Ташламалы аренда түләвен билгеләү, муниципаль милектәге торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын арендага бирү тәртибе турында» 2018 елның 27 августындагы 156 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2025елның 16 маендагы 667 номерлы карарының 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2018елның 27 августындагы 156 номерлы карары белән расланган муниципаль милеккә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын ташламалы аренда түләвен билгеләү, арендага бирү тәртибенә (алга таба-нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктның өченче абзацында «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 29 июнендәге 646 номерлы карары белән расланган мәдәни мирас объектларын «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-Фз номерлы Федераль законда билгеләнгән мәдәни мирас объектларына кертү критерийларын раслау хакында» сүзләрен «канәгатьләнерлек хәлдә булган мәдәни мирас объектларына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы муниципаль районы
Советы рәисе Н.А.Вазыйхов